СОВЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**26 октябрь 2015 ел** Болгар ш. **№ 2-2**

**Спас муниципаль районы Советының 2013 елның 28 октябрендәге 35-3 номерлы карары белән расланган «ТР Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 30 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 4 октябрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «ТР Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

- бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм районның салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- «районның социаль-икътисадый үсеше фаразы»;

- муниципаль программалар (муниципаль программалар проектларында, күрсәтелгән программаларның үзгәрешләр проектларында)».

2) 23 статьяның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- "Бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм районның салым сәясәтенең төп юнәлешләре".

2. Әлеге карар халыкка игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының spasskiy.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Спас муниципаль районы башлыгы** **К. А. Нугаев**